ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 апрель 2018 ел № 1950

Яр Чаллы шәһәренең «Р.С. Хәмәдиев исемендәге «Тулпар» балалар-яшүсмерләр ат спорты мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 17 маддәсендәге 1 бүлекнең 4 пунктына, шәһәр Уставының 41 маддәсенә, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 нче карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезнамәнең 5 пунктына. Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турындагы нигезнамәгә туры китереп

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Р.С. Хәмәдиев исемендәге «Тулпар» балалар-яшүсмерләр ат спорты мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастыруны һәм «Интернет» челтәрендә рәсми сайтта урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 10 апрелендәге
1950 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Р.С. Хәмәдиев исемендәге «Тулпар» балалар-яшүсмерләр ат спорты мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| Т/с | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе, сум |
|---|---|---|---|
| 1. | Спорт атларына атланып йөрергә өйрәтү буенча инструктор белән индивидуаль тренировка дәресләре | 1 сәгать | 800 |
| 2. | «Тулпар» ат спорты мәктәбе» - «Яр буе» паркы маршрутлары буенча инструктор ярдәме белән атка атланып йөрү, шул исәптән: спорт атына зурлар / понига – балалар | 1 маршрут/ 1 сәгать | 300 / 200 |
| 3. | Спорт-массакүләм чаралары (мәктәпнең ат спорты комплексы территориясендә экскурсия хезмәтләре) | 1 маршрут/ 0,5 сәгать | 100 |
| 4. | Шәһәр чараларында инструктор ярдәме белән спорт атларына һәм экзотик хайваннарга атланып йөрү, шул исәптән: | 1 маршрут/ 1 сәгать | |
| - | спорт атына (балалар/зурлар) | | 100 / 200 |
| - | дөягә (балалар/зурлар) | | 200 / 300 |
| - | понига, ишәккә (балалар/ -) | | 100 / - |
| 5. | Шәһәр чараларында инструктор ярдәме белән балалар юлларында чанада, фаэтонда, каретада йөрү | 1 урын/ 1 маршрут | 100 |
| 6. | Мөлкәтне арендага бирү, шул исәптән спорт инвентарен (фигуралы шуу буенча тимераякларны) прокатка бирү, балалар/зурлар | сәгать | 70/100 |
| 7. | Туй тантаналары | 1 чара | 3000 |
| 8. | Хезмәтләрдән файдаланучыларның транспорт чараларын кую урыны хезмәтләре, шул исәптән: | | |
| 8.1. | Кыска сроклы килешүләр буенча тәүлеклек парковка – җиңел автотранспорт, микроавтобус өчен (бер тапкыр) | тәүлегенә 1 машина/урын | 50 |
| 8.2. | Кыска сроклы килешүләр буенча тәүлеклек парковка – пассажирлар автотранспорты (автобус) / йөк автотранспорты өчен (бер тапкыр) | тәүлегенә 1 машина/урын | 100 |
| 8.3. | Озак сроклы килешүләр буенча парковка – җиңел автотранспорт Ока/ВАЗ/ГАЗ/чит ил автомобильләре өчен | аена 1 машина/урын | 650/750/800 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8.4. | Озак сроклы килешүләр буенча парковка – Микроавтобус / Кроссовер / Паркетник / Юлдан тыш урыннарда йөрүче автомобиль / Пикап / Газель / Соболь өчен | аена<br>1 машина/урын | 850 |
| 8.5. | Озак сроклы килешүләр буенча парковка – пассажирлар автотранспорты – ПАЗ, ЗИЛ, ВалДай, Бычок автобуслары өчен | аена<br>1 машина/урын | 1200 |
| 8.6. | Озак сроклы килешүләр буенча парковка – йөк автотранспорты – КамАЗ, МАЗ өчен | аена<br>1 машина/урын | 1300 |
| 8.7. | Озак сроклы килешүләр буенча парковка – җиңел тагылмалар өчен | аена<br>1 машина/урын | 500 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова